ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

## 1 статья

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, №7–8 (I өлеш), № 9–10, № 12 (I өлеш); 2010, №1–2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1–2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7–8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 2.18 статьяны өстәргә:

«2.18 статья. **Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе карарын яисә күрсәтмәсен үтәмәү**

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе карарын яисә күрсәтмәсен үтәмәгән йә үтәү срогын бозган өчен, административ хокук бозу турындагы эш буенча карардан йә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 29.13 статьясында каралган тәртиптә чыгарылган күрсәтмәдән тыш, –

гражданнарга – бер меңнән алып ике мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – ике меңнән алып биш мең сумга кадәр, юридик затларга ун меңнән алып егерме мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.17» саннарын «2.11 – 2.18» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^2$ өлеш өстәргә:

«$7^2$. Әлеге Кодексның 2.18 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча тиешле комиссияләрнең рәисләре, аларның урынбасарлары төзи.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 72-ТРЗ